| СОВЕТ<br>НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>ЯР БУЕ МОРКВАШЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|
| Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594 | Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Морквашы авылы, 422594 |

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

26.10.2023 с. Набережные Моркваши 39-230

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

### Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2023 елның 06 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясендә гражданнар арасында үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 10 000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән сез килешәсезме:

-Яр буе Морквашы авылы Калуга урамында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Яр буе Морквашы авылы, Красавин ур., 40 йорт адресы буенча (Башкарма комитет бинасы)11.00 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х. Гаязов